Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №II-2**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 6 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә ачык (гавами) тыңлауларны (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә ачык (гавами) тыңлауларны (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 6 маддәнең 1 пунктындагы 1.1 пунктчасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.1 Ачык (гавами) тыңлауларның нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, гаммәви мәгълүмат чараларында, муниципаль районның рәсми сайтында һәм (яисә) башка мәгълүмат системаларында һәм мәгълүмат стендларында бастырып чыгарыла (игълан ителә).”.

2. Карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов